**КАЙБЕР ТАТАР РИЗЫК АТАМАЛАРЫНА ЛИНГВОМӘДӘНИ КҮЗӘТҮ**

*Нурмөхәммәтова Р.С., Казан, КФУ, филол. фән. канд., доцент*

Статья посвящается изучению некоторых единиц лексики материальной культуры. В ней дано лингвокультурологическое описание таких названий национальных татарских блюд, как *кыстыбый, җәймә, дучмак.*

**Ключевые слова:** лексика материальной культуры, пищевые традиции, названия пищи, лингвокультурологическое описание.

Азык-төлек – кешенең төп биологик ихтыяҗларыннан берсен тәшкил итә. Кешелек әйләнә-тирәсендәге күп кенә табигый байлыкларны (үсемлекләрне, җиләк-җимеш, яшелчә, хайваннарны һ.б.) үзенең әлеге ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен файдаланырга өйрәнгән. Әмма ризыкны куллану-әзерләүгә бәйле гореф-гадәтләрдә теге-яки бу мохиткә хас ресурслар гына түгел, бәлки халыкның күп кенә мәдәни үзенчәлекләре дә туплана. Шуңа күрә аларга аеруча сак мөнәсәбәт таләп ителә.

Теләсә кайсы илдә һәм теләсә кайсы чорда матди мәдәниятнең иң тотрыклы элементлары – ашау-эчү традицияләре. Татарлар – тарих дәвамында табигый һәм иҗтимагый-икътисади шартларга бәйле шактый үзгәрешләр кичергән халык. Әлбәттә, болар татар халкының милли ризыклары язмышына да тәэсир иткән: күп кенә ризыкларны әзерләү тәҗрибәсе буыннан-буынга күчми калган, кайберләре матди яктан яңа эчтәлек алган, чит халыклардан кергән ризыклар үзләштерелгән. Әмма шундый шартларда да татар халкының элек-электән килгән матди һәм рухи байлыгын үзләрендә саклап калган ризыклар күпсанлы. Бу ризыкларны әзерләү үзенчәлекләре һәм аларның атамалары буыннар тәҗрибәсен, татарларның тормыш итү рәвешен, андагы үсеш-үзгәрешләрне ачык чагылдыра. Шундыйларның берсе – *кыстыбый.* Ул иң борынгы һәм гади ризыклардан санала.

*Кыстыбый* өчен табада төче камырдан юка итеп җәеп тышлык пешерелә, аның эченә бәрәңге, тары боткасы яисә төйгән киндер орлыгы салына. Баштарак ул камыр эченә төрле ярмалардан пешерелгән боткалар салып әзерләнгән. Әгәр татар халкының элек-электән игенчелек белән шөгыльләнүен искә төшерсәк, бу гаҗәп түгел. Бәрәңге Россиядә, шул исәптән татар халкында XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында гына ныклап урнаша. Кыстыбый да бәрәңге эчлеге белән XIX гасыр азагыннан гына әзерләнә башлый [branclub.narod.ru]. Кыстыбыйның эчлегенә карап, төрле төбәкләрдә *бәрәңге кыстыбые, орлык кыстыбые, тары кыстыбые* кебек атамаларны очратырга була.

Кыстыбый атамасының килеп чыгышына килгәндә, Р.Әхмәтьянов аны “кыс-у” фигыленә ниндидер -*мбый/-мби* аффиксы өстәлеп ясалган булырга тиеш дип аңлата [Әхмәтьянов 2001: 136]. Ризыкны әзерләү технологияләре күзлегеннән бу аңлатма дөреслеккә шактый якын: ул камыр арасына алда атап үтелгән эчлекләрнең кайсын да булса *кыс*тырып ясала. Р.Әхмәтьянов та, Ф.Баязитова да кыстыбый сүзенең башка күрше халыкларга керүенә игътибар итәләр: башкортча *ҡыстымбый*, чуваш диалектларында *кастампи*, мари телендә *кыстывий*, удмуртларда *кыстыбый* [Баязитова 2007: 251].

Кыстыбый татарлар яши торган барлык җирләрдә дә таралган. Бу факт та аның борынгы ризык икәнен раслый. Җирле төбәкләрдә ул башкачарак та атала: казан арты, минзәлә, керәшен сөйләшләрендә – *күзикмәк* [ТТЗДС, 346], норлат, тархан, әстерхан сөйләшләрендә – *якмыш* [ТТЗДС, 227]. 2007 елгы татарча-русча сүзлектә *тәбикмәк* сүзе кыстыбый дип шәрехләнгән [ТРС 2007: 333]. Бу атамалар да үзләрен аклый: кыстыбый камырын кызган табада пешергәндә күз-күз кызгылт эзләр кала: күзле икмәк > *күзикмәк*; *якмыш* сүзенең нигезендә “як(г)-у” фигыле ята; *тәбикмәк* > таба икмәге, чыннан да кыстыбыйның камыр өлеше (тышы) табада пешерелә. Түбән сөйләшендә *капшырма* сүзе кыстыбый мәгънәсендә йөри [Баязитова 2007: 229].

Кыстыбый сүзе XX-XXI гасырда чыккан татар сүзлекләренең барысында да диярлек урын алган. Болар да кыстыбыйның озак еллар дәвамында популяр булып калуын раслый. Мәсәлән (татарча-русча сүзлекләрдәге аңлатмалар русчадан тәрҗемә итеп бирелә – Н.Р.): قستبي (ТРС 1927: 155), qstьbi [ТРС 1931: 245] – ботка яки бәрәңгедән юка гына эчлек салынган пирог; пирог (эченә ботка яки бәрәңге боламыгыннан юка эчлек салынган) [ТРС 1950: 167]; кыстыбий (эченә ботка яки бәрәңге боламыгыннан юка эчлек салынган, читләре ачык, ябыштырылмаган пирог) [ТРС 1966: 314]; уртага бөкләнгән юка камыр эченә изгән бәрәңге, тары боткасы, төелгән киндер орлыгы яки мәк орлыгы һ.б. салып пешерелгән ашамлык [ТТАС 1979: 206]; кыстыбый (милли ашамлык) [ТРС 1988: 184]; уртасыннан бөкләгән юка камыр эченә бәрәңге, тары боткасы яисә төйгән киндер орлыгы салып пешерелгән ашамлык [ТТАС 2005: 311]; кыстыбый (гадәттә эченә бәрәңге салынган пирог төре) [ТРС 2007-I: 708]. Сүзлек мәкаләләренә күз салсак, аларда бу төр ризыкның эчлеге бәрәңге, тары боткасы, төелгән орлыклардан әзерләнүенә басым ясалуы күренә. Әмма соңгы елларда күбрәк бәрәңге кыстыбыйлары пешерелә, бу үзенчәлеккә 2007 елгы сүзлектә игътибар ителә.

Татар мәкальләре һәм фразеологизмнары составында кыстыбый сүзенең очравы да бу ризыкның борынгылыгына күпмедер ишарә итә: *Кысылма, **кыстыбыең** сытылыр* (1216), *кысылма, **кыстыбый** булырсың, **кыстыбый** кебек кысылып йөрмә!* (29194) мәкальләре һәм *кыстыбый кебек кысылу* (б.435) фразеологизмы кеше эшенә тыгылу, урынсызга сүзгә килеп кысылу очракларына карата әйтеләләр.

“Аю белән кешенең дуслыгы кайчан беткән” дип аталган татар халык әкиятендә дә бу сүз очрый, әмма әлеге ризык анда башкачарак “әзерләнә”: *“Аю шалканны бик яраткан, ашаган-ашаган да, бик тәмле булды, рәхмәт, дип кайтып киткән. Инде хәзер аю да кешене чакырган. Ул да, мескен, төрле аш ясыйм дип, шалканның яфракларын турап-турап шулпа итеп тә, урап-урап* ***кыстыбый*** *итеп тә пешергән”.*

Бу ризык атамасы татар язучыларының әсәрләрендә дә күзәтелә. *Аңа игътибарлы булыгыз. Ач вакытларымда Мөхәммәд Гариф мине Кушлавычка алып кайта иде, әбиең мине* ***кыстыбый****, бәлеш, каклаган каз белән сыйлый иде* (Р.Батулла “Апуш-Тукай”). *Рәйхан сәкегә ашъяулык җәя. Самавыр утырта, зур табак белән аш куя,* ***кыстыбый****, вак бәлешләр куя. Миңлебай башта табагы белән алып ашны ашап бетерә. Аннан соң икенче табактагы вак бәлешләрне ашап куя. Таба белән өелеп торган* ***кыстыбый****ны үзенә тартып китерә дә аны да ашап бетерә* (З.Зәйнуллин “Кырык бернең арбалы хатыннары”). *Өйләрендә әллә никадәр җиһазлар булмаса да, җәмәгатьләре шул карт-карчык берлән бетсә дә, Гөлйөзем әби көн буе эштән бушамый иде. Ул кайвакытлар мич ягып күмәч сала,* ***кыстыбый*** *пешерә, бәйрәм көннәрендә картының намаздан кайтуына коймак хәзерләп куя иде* (Г.Исхакый “Сөннәтче бабай”).

Әдәби әсәрләр буенча фикер йөртсәк, камыр уртасына тапалган ит ягып пешерелгән ризыкны да кыстыбый дип атауларын күрергә мөмкин.

– ***Кыстыбый*** *пешер әле син миңа! – дип ярып салды Мөбарәк.*

*– Ярар... пешерермен... – диде чибәр хатын көттереп кенә. – Ә... нәрсә* ***кыстыбые*** *пешерим соң?!* <...>

*Мөбарәкнең* ***ит кыстыбые*** *ратканын белә иде Нурсадә. <...>Нурсадә* ***тары*** *һәм* ***бәрәңге кыстыбыйларын*** *майлап торганда, дәү җиз самавыр кайнап чыкты* (М.Шаһимәрдән “Татылу”).

Татарларда кыстыбый тышы (камыры) аерым ризык буларак та кулланыла. Аны кайбер төбәкләрдә *юка* (җука, йука, йока, юкамыш) дип йөртәләр (атама камыр юка гына итеп табада пешерелгән булудан килеп чыккан булырга тиеш).

Төче камырдан юка итеп җәеп пешерелгән камыр ашы (шулай ук кыстыбый тышына охшаган) мишәр диалекты сөйләшләрендә *зәймә, йәймә*, себер диалектында *йәймә* сүзе белән белдерелә [Баязитова 2007: 254]. Әдәби телдә бу ризыкның исеме – *җәймә* (атама нигезендә “җәй-ү” фигыле ята). Бу берәмлек тә мәкальләрдә очрый: *Тышы* ***җәймә*** *җәя, эче пилмән бөгә* (1489); *Эчем бөккән бөгә, тышым* ***җәймә*** *җәя* (1492); *Эчтән умач уа, тыштан* ***җәймә*** *җәя* (1497) һ.б. мәкальләр икейөзлелек яки сер бирмәүчелеккә мисал йөзеннән әйтеләләр.

Бу сүз дә төрле чорларда иҗат ителгән матур әдәбият әсәрләрендә урын алган. *Ишек тирәсендәге халык ач күзләрен парланып торган майлы итләргә текәделәр, түрдәге табынга туралмаган симез тукты, казылык белән түбәләмә тулы табакны китереп утырттылар. Иң өстә көйдерелеп пешерелгән куй башы, азрак* ***җәймә*** *бар иде* (Г.Ибраһимов “Казакъ кызы”). *Көз булганлыктан, ашау ягы бик бай булмаса да, ярыйсы гына күренә. Әрчеп пешергән ярмалы бәрәңге, берничә* ***җәймә****, азрак каймак, сөтле чәй* (З.Зәйнуллин “Сугыш алды малайлары”). *Тутасы җибәргән оннан көнбагыш маенда булса да,* ***җәймә*** *катырып алды* (А.Хәлим “Өч аяклы ат”).

Татар табыны бер үк төрле компонентлардан әзерләнгән ризыкларга гаять бай. Кыстыбыйга охшаган, әмма ачык итеп пешерелә торган тагын бер милли ризык – *дучмак*. Бу – түгәрәкләп җәйгән камыр өстенә изгән бәрәңге, эремчек һ.б. нәрсә ягып пешерелгән таба ашы [ТТАС 1977: 315]. Кыстыбый һәрвакыт төче камырдан әзерләнсә, дучмакны әче камырдан да, төче камырдан да пешерәләр. Гәрчә сүзлекләргә “*диалекталь*” тамгасы белән теркәлмәсә дә, кайбер галимнәр бу сүзнең әдәби телдә очрамавын, төрле урынчалыкларда *дучмак / дурычмак / дүртпочмак* вариантларында йөрүен искәртеп, җирле сөйләш берәмлеге булуын күрсәтәләр [Юсупова 2008: 162-163]. “Татар халык ашлары” хезмәтендә бу ризыкның *йомырка дучмагы, бәрәңге дучмагы* кебек төрләре тасвирланган [Әхмәтҗанов 1999: 135]. Т.Хәйретдинова хезмәтендә ул “шакмак рәвешендәге пирог” дип бирелә һәм *дучмак / дурычмак* атамасы “дүрт” һәм “почмак” сүзләренең кушылмасыннан килеп чыккан дип аңлатыла: *дүртпочмак > дурочмак > дучмак* [Хайрутдинова 1993: 39]. Шулай да ул күп кенә төбәкләрдә түгәрәк итеп пешерелә. Диалектологиягә караган хезмәтләрдә бу сүзнең түбән кама керәшеннәре, казан арты-мамадыш, нагайбак керәшеннәре, минзәлә сөйләшендә очравы әйтеп үтелә [Баязитова 2007: 207]. Кызганыч, бу берәмлек мәкаль-әйтемнәрдә табылмады. Гәрчә бу ризыкның аерым төрләре (мәсәлән, эремчек эчлеге белән пешерелгәне) гаять киң таралган булса да, ул әдәби әсәрләрдә дә аз очрый. *Әнисе* ***дучмак*** *пешерергә җыена ахрысы, камыр җәюеннән туктап, куна тактасыннан он сыпырып төшерде. Ә хәзер, әнә, тукмак белән бәрәңге изә башлады. <...> Әнисе һаман мич янында кайнаша. Өйгә* ***дучмак*** *исе таралган. Авыз суларын китереп тора. <...> – Миңлегаяз йоклыйдыр әле... Яшь киленнәре суга төшеп бара, ә син тор дисең, – дип сөйләнде малай, кайнар* ***дучмак*** *исен киерелеп сулый-сулый. <...> Җылы пар бөркеп өстәлгә ак самавыр менеп утырды, олы бадьянга өелгән* ***дучмак*** *куелды* (Р.Мөхәммәдиев “Ак кыялар”).

Пешерелүе һәм компонентлары белән *дучмак / дурычмак*ка охшаган ризык красноуфим, пермь, нократ сөйләшләрендә исә *шаңгә / шаңкә / шанги* сүзләре белән белдерелә; аны бәрәңге (*йиралма* яки *картүк шаңгә*), гөмбә (*мәшкә шаңгә*), кишер (*сары торма шаңгә*), җир җиләге (*шартлама шаңгә*), кура җиләге (*өмөҗе шаңгә*), шомырт, угыз эремчеге (*ывыз шаңгә*) һ.б. белән пешерәләр [Баязитова 2007: 209-212]. *Нәстүк сәкегә ашъяулык сыман тукыма җәеп, туралган чөгендер һәм кичә Кәбир күчтәнәч итеп биргән бәрәңгене кушып пешергән кайнар* ***шаңгә*** *китереп куйды* (А.Хәлим “Өч аяклы ат”).

Бу ашамлык рус халкының “ватрушка” дип аталган ризыгына берникадәр охшаган, шуңа күрә татарча-русча сүзлекләрдә шулай тәрҗемә итеп бирелә дә: دورچماق – ватрушка [ТРС 1927: 113]; durcmaq – ватрушка [ТРС 1931: 94]; ватрушка [ТРС 1950: 109; ТРС 1988: 88]; ватрушка (творог, бәрәңге боламыгы, йомырка һ.б. белән әзерләнгән) [ТРС 1966: 137]; творог, бәрәңге боламыгы, йомырка һ.б. белән әзерләнгән ватрушка, шәнгәгә охшаган камыр ашы [ТРС 2007-I: 363].

Шул рәвешчә, ризык атамаларында халыкның күпгасырлык тормыш тәҗрибәсе, яшәү шартларына бәйле сыйфатлары чагылыш таба. Лексиканың әлеге катламын өйрәнү һәм билгеле бер тәртипкә салу, системалаштыру зарурлыгы тел белеме фәненең үсеше һәм халыкның тормыш шартлары үзгәрү белән аңлатыла. Мондый тикшеренүләр этносның матди һәм рухи байлыгы формалашу хакында бай материал бирә; гасырлар дәвамында формалашкан һәм яшәү шартларына бәйле рәвештә берникадәр үзгәрешләр кичергән милли үзенчәлекләрне саклап калуда, киләчәк буыннарга җиткерүдә зур роль уйный дип уйлыйбыз.

ӘДӘБИЯТ:


1. Әхмәтҗанов Ю.Ә. Татар халык ашлары. – Казан: Раннур, 1999. – 464 б.
2. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.
3. Баязитова Ф.С. Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. – Казан: Дом печати, 2007. – 480 б.
4. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 1 т. (А-К), 2 т. (Л-Һ). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.
5. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.
6. Хайрутдинова Т.Х. Названия пищи в татарском языке. – Казань, 1993. – 142 с.
7. Юсупова А.Ш. Двуязычная лексикография татарского языка XIX века. – Казань: Изд-во Казанск. гос. ун-та, 2008. – 410 с.
8. branclub.narod.ru.


ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР:


ТРС 1927 – Татарча-урысча сүзлек / Төз. М.Корбангалиев, Р.Газизов, И.Күлиев. – Казан: Татарстан дәүләт нәшр., 1927. – 219 б.

ТРС 1931 – Татарча-урысча сүзлек (төзәтелгән һәм арттырылган 2 нче басмасы) / Төз. М.Корбангалиев, Р.Газизов, И.Күлиев. – Казан: Татиздат, 1931. – 410 б.

ТРС 1950 – Татарча-русча сүзлек / Төз. Р.Газизов, Н.Исәнбәт, Г.Ишмөхәммәтов. – Казан: Татгосиздат, 1950. – 339 б.

ТРС 1966 – Татарча-русча сүзлек. – М.: “Советская энциклопедия” нәшр., 1966. – 864 б.

ТРС 1988 – Татарча-русча сүзлек / Төз. И.А.Абдуллин, Ф.А.Ганиев, М.Г.Мөхәмәдиев, Р.А.Юналеева. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1988. – 462 б.

ТРС 2007 – Татарско-русский словарь: В 2-х т. Т.1 (А-Л), Т.2 (М-Я) – Казань: Алма-Лит, 2007.

ТТАС 1977, 1979 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т.1. – Казан: Тат.кит. нәшр., 1977. – 475б.; Т.2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 726 б.

ТТАС 2005 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

ТТЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.


## ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКОЕ ОПИСАНИЕ НЕКОТОРЫХ НАИМЕНОВАНИЙ ТАТАРСКИХ БЛЮД

*Нурмухаметова Р.С.*

## LINGUACULTUROLOGICAL DESCRIPTION OF DENOMINATION OF SOME TATAR DISHES

*Nurmukhametova R.S.*

The article is devoted to the study of some vocabulary items in material culture. The author throws light upon the linguaculturological description of denominations of such national Tatar dishes as kystyby, zhaima, duchmak.

**Key words:** vocabulary of material culture, food tradition, the names of the food, linguaculturological description.